# КАРАР

**21 март 2022 ел** **№ 7**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылында «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Кызыл Чәчәк авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 21 март түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Кызыл Чәчәк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

2 пунктта «6500 сум» сүзләрен «2000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

«су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү өчен проект-смета документациясен эшләү, су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

- вак таш җәю һәм юлларны карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 39 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 21.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 21 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Кызыл Чәчәк авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Кызыл Чәчәк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

2 пунктта «6500 сум» сүзләрен «2000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

«су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү өчен проект-смета документациясен эшләү, су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

- вак таш җәю һәм юлларны карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы: В.В.Васильев